ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2019 г. Заинск № 521

**“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында“**

«Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 44нче Федераль Законны (5 апрель, 2013) үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45нче маддәсенә нигезләнеп, Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

## карар бирә:

1.Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә әлеге карар (алга таба – муниципаль сатып алулар) җирле бюджетлар һәм финанслауның бюджеттан тыш чыганаклары исәбенә, 44нче федераль законның 93нче маддәсе 4нче, 5нче пунктларын исәпкә алмаганда, башкарыла.
2.Расларга:
- муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә товар белән тәэмин итүчеләрне билгеләүгә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән үзара хезмәттәшлек турында Положениене 1нче кушымта нигезендә;
- муниципаль ихтыяжлар өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында Положениене 2нче кушымта нигезендә;
- бердәм комиссия әгъзалары составын 3нче кушымта нигезендә;
- заказчылар белән төзелгән муниципаль контрактлар реестры турында Кагыйдәләрне 4нче кушымта нигезендә;
- районның муниципаль заказчылары реестрын – берләштерелгән бюджет средстволарын бүлүчеләрне 5нче кушымта нигезендә;
- мунициапль ихтыяҗлар өчен бердәнбер товар җибәрүчеләр (эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче) исемлеген 6нчы кушымта нигезендә.
3. Билгеләргә:
- башкарма комитетның муниципаль заказ бүлегенә вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль заказчылар өчен (алга таба – вәкаләтле орган) товар җибәрүчеләрне (подрядчы, башкаручы) билгеләргә;

-сатып алуларның планлаштыру, сатып алуларга заявкалар бирү өчен җаваплы муниципаль заказчыларны билгеләргә (шул исәптән техник задание, башлангыч бәягә нигезләмә, төзелгән контракт турында мәгълүмат (аларның үзгәрүе, өзелүе һәм башкарылышы).

4. «Интернет» челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты белән муниципаль сатып алуларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен www.zakupki.gov.ru сайтын билгеләргә.

5. Республика Казначылык департаментының Зәй территориаль бүлегенә сатып алу чыгымнары лимитын контрольдә тотарга һәм төзелгән муниципаль контрактларга түләүне гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

6. Муниципаль заказчыларга:

– төзелгән килешүләр нигезендә үз вакытында сатып алуларны планлаштыруны, төзелгән контрактлар турында мәгълүматны, шулай ук заявкаларны, техник заданиене, башлангыч бәянең нигезләмәсен, контрактларның проектларын һәм башка документларны урнаштырырга.

– приказ белән сатып алу мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү өчен контрактлы идарәчене билгеләргә.

7. Муниципаль район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында“ 1187нче (18.07.2018) карарын (муниципаль район башкарма комитетының 1851нче (13.12.2018), 15нче (25.012019), 146нчы (21.03.2019), 288нче (31.05.2019), 440нчы (19.08.2019) карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) гамәлдән чыккан дип санарга.

8. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы рәсми хокукый портал”ында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.

9. Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне башкарма комитет җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә булышлык буенча урынбасары М.И.Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист

Е.А. Улитина
3 79 17